**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының В.Е. Алемасов исемендәге дәүләт премиясен гамәлгә кую турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «В.Е. Алемасов исемендәге Татарстан Республикасы Дәүләт премиясен гамәлгә кую турында» 2014 елның 22 сентябрендәге ПУ-913 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2016 елның 22 февралендәге ПУ-200 номерлы, 2018 елның 13 апрелендәге ПУ-309 номерлы, 2020 елның 29 гыйнварындагы ПУ-41 номерлы, 2021 елның 14 июлендәге ПУ-579 номерлы, 2022 елның 28 июнендәге ПУ-441 номерлы указлары, Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 11 июлендәге 484 номерлы, 2024 елның 19 гыйнварындагы 40 номерлы, 2024 елның 5 августындагы 592 номерлы һәм 2024 елның 12 декабрендәге 947 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Татарстан Республикасының В.Е. Алемасов исемендәге дәүләт премиясе турында нигезләмәнең 5 пунктындагы беренче абзацта «1 майга кадәр» сүзләрен «1 апрельгә кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

б) Татарстан Республикасының В.Е. Алемасов исемендәге дәүләт премиясен бирү комитеты (алга таба – Комитет) составында Комитет әгъзалары вазыйфалары атамаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

А.О. Гариповның – «Казан вертолет заводы» акционер җәмгыяте генераль директоры урынбасары – тәҗрибә-конструкторлык бюросы баш конструкторы (килешү буенча)»;

Ю.И. Герасимовның – «КАМАЗ» гавами акционер җәмгыяте генераль директорының автокомпонентлар буенча урынбасары (килешү буенча)»;

Ю.Ф. Гортышовның – «А.Н. Туполев исемендәге Казан илкүләм тикшеренү техник университеты-КАИ» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең җылылык техникасы һәм энергетика машиналары төзү кафедрасы профессоры (килешү буенча)»;

Б.И. Найшулерның – «Туполев» акционер җәмгыяте филиалы – С.П. Горбунов исемендәге Казан авиация заводының техник яктан яңадан җиһазландыру һәм яңа эшләнмәләр буенча директоры (килешү буенча)».

2. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2026 ел, 03 февраль
№ 93